КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 16 март г.Казань № 136

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 ел, 10 сентябрь, 625 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның

кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 ел, 10 сентябрь, 625 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 20 декабрь, 959 нчы; 2017 ел, 28 март, 193 нче; 2019 ел, 20 декабрь, 1174 нче; 2020 ел, 17 апрель, 304 нче; 2020 ел, 5 ноябрь, 999 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында»;

әлеге карар белән расланган Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү тәртибендә 5.15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.15. Әгәр дә эшкә сәләтле гражданның (гомуми белем бирү оешмасында яисә һөнәри белем бирү оешмасында яки югары белем бирүче мәгариф оешмасында көндезге формада белем алучы 18 яшькә кадәрге эшкә сәләтле заттан тыш) кереме балага айлык пособие билгеләү турында гариза биргән датага эшкә сәләтле халыкның яшәү минимумы күләменең 70 процентыннан кимрәк булса, гражданның кереме сыйфатында балага айлык пособие билгеләү турында гариза биргән датага эшкә сәләтле халыкның яшәү минимумы күләменең 70 проценты исәпкә алына.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин